ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИУИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӨРКЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

15 июнь 2022 ел №11

Өркеш авыл җирлеге Советның аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Өркеш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- « Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затлар тарафыннан үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 апрелендәге 12 номерлы карары;

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 8 номерлы карары;

- Өркеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 июнендәге 9 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: А.Ш.Әгъләмова